**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Березняк авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**3 декабрь, 2024 ел** **№ 9**

**Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Березняк авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 17 декабрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Березняк авылы, Ленин урамы, 17 адресында урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 17 декабрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Березняк авылы, Ленин урамы, 17 адресында урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

3. 2024 елның 17 декабрендә 15 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Березняк авылы, Ленин урамы, 17 адресында урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

4. 2024 елның 17 декабрендә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Березняк авылы, Ленин урамы, 17 адресында урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Березняк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә

чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау** (янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

**- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау**(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, шәхси электр белән тәэмин итү өчен генератор сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Березняк авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре); (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

**- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Березняк авылы чишмәсе территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмә территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- торак пункт территориясен төзекләндерү *(*** Березняк авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүлү.

7. Березняк авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

8. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

9. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Березняк авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Шәрипов